КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2026 ел, 21 гыйнвар г.Казань № б-49

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 20 гыйнвар, б-75 нче боерыгы белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 6 март, б-566 нчы; 2023 ел, 29 декабрь, б-3264 нче; 2025 ел, 25 гыйнвар, б-111 нче боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2023 – 2034 елларга Татарстан Республикасы Бюджет фаразына, аны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 20 гыйнвар, б-75 нче
боерыгы белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2026 ел, 21 гыйнвар, б-49 нчы
боерыгы редакциясендә)

# 2023 – 2034 елларга Татарстан Республикасының бюджет фаразы

2023 – 2034 елларга Татарстан Республикасының бюджет фаразы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Озак сроклы чорга Татарстан Республикасының бюджет фаразын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2015 ел, 15 сентябрь, 676 нчы карары белән расланган Озак сроклы чорга Татарстан Республикасының бюджет фаразын эшләү һәм раслау тәртибенә нигезләнеп эшләнде.

Бюджет фаразында 12 елга, ягъни 2034 елга кадәрге чорга бурыч, салым һәм бюджет сәясәтенең төп юнәлешләре һәм Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының төп параметрлары билгеләнә.

Бюджет фаразын формалаштыру алымнары үткән еллардагы республика бюджет сәясәтен гамәлгә ашыру йомгакларына нигезләнә.

## Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты үтәлешенең төп йомгаклары

2023 – 2024 елларда Татарстан Республикасы бюджеты үтәлеше гомумроссия масштабында да, шулай ук региональ дәрәҗәдә дә икътисад үсешенең гади булмаган шартларында гамәлгә ашырылды, аңа Россия Федерациясенә карата чит ил дәүләтләре тарафыннан катлаулы геосәяси вәзгыять, озак дәвамлы санкция басымы һәм административ чикләүләр йогынты ясады. Шул ук вакытта тулаем алганда 2023 – 2024 елларда республика икътисады үсешенең төп күрсәткечләре буенча уңай динамика күзәтелде.

2023 елда Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына 481,1 млрд.сум күләмендә салым һәм салым булмаган керемнәр керде, бу 2022 елга караганда 51,7 млрд.сумга (12 процентка) күбрәк.

2023 елда инфраструктура үсеше чараларын гамәлгә ашыру кысаларында федераль бюджеттан 10,4 млрд.сум күләмендә озак сроклы бюджет кредитлары җәлеп ителде. Шулай ук Татарстан Республикасы «Торак», «Заманча мәктәп», «Мәдәни мохит», «Сәламәтлек саклауның беренчел звеносын модернизацияләү», «Региональ һәм җирле юл челтәре» федераль проектларын республика территориясендә гамәлгә ашыру кысаларында объектларны төзү һәм капиталь ремонтлау буенча Татарстан Республикасының чыгым йөкләмәләрен алга китеп финанс белән тәэмин итү максатларында федераль бюджет чараларын 15,0 млрд.сум күләмендә җәлеп итүнең кире кайтару механизмыннан файдаланды.

2023 ел йомгаклары буенча бурыч йөкләнеше дәрәҗәсе Татарстан Республикасы бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәре күләменең 30,9 процентын тәшкил итте, бу федераль бюджет кредитлары буенча бурычларны реструктуризацияләү кысаларында республика өчен билгеләнгән максатка ярашлы максатчан күрсәткечне (2023 елга иң чик рөхсәт ителә торган дәрәҗә 43 процент тәшкил итте) ышанычлы үтәргә мөмкинлек бирде.

2024 елда Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына 593,4 млрд.сум күләмендә салым һәм салым булмаган керемнәр керде, бу 2023 елга караганда 112,3 млрд.сумга (23 процентка) күбрәк.

2023 – 2024 елларда Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты чыгымнарын финанслау кысаларында социаль йөкләмәләрне тулысынча үтәү өстенлекле тәртиптә тәэмин ителде.

Шулай ук башка юнәлешләр дә, шул исәптән капиталь характердагы чыгымнар да, тиешле финанслау белән тәэмин ителде. Шул ук вакытта, узган еллардагы кебек үк, республика бюджетын үтәү базар характерындагы заем чыганакларыннан файдаланмыйча башкарылды. 2024 елда федераль бюджеттан бюджет кредитлары җәлеп ителмәде.

2024 ел йомгаклары буенча Татарстан Республикасы бюджеты профицит белән үтәлде, бурыч йөкләмәсенең дәрәҗәсе Татарстан Республикасы бюджетының салым һәм салым булмаган керемнәр күләменнән 22,5 процентка кадәр кимүе тәэмин ителде, бу федераль бюджет кредитлары буенча бурычларны реструктуризацияләү кысаларында республика өчен билгеләнгән максатка ярашлы күрсәткечне ышанычлы үтәргә мөмкинлек бирде (2024 елга иң чик рөхсәт ителә торган дәрәҗә 40 процент тәшкил итте).

## Озак сроклы чорда салым, бюджет һәм бурыч сәясәтен формалаштыруга карата төп алымнар

Озак сроклы чорда Татарстан Республикасының салым, бюджет һәм бурыч сәясәтен гамәлгә ашыруның төп максатлары бюджет системасының тотрыклылыгын һәм баланслыгын саклау, халыкның яшәү сыйфатын күтәрү булып тора.

Фаразлана торган чорда салым сәясәтен гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты керемнәре, икътисад секторларына салым салуның төп параметрларын саклауны исәпкә алып, 2034 елга кадәрге чорга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерүнең төп күрсәткечләрен бәяләүдән чыгып билгеләнә. Салым һәм салым булмаган керемнәрне фаразлаганда узган елларда барлыкка килгән тенденцияләр, геосәяси факторларның тулаем дәүләтнең социаль-икътисадый үсешенә йогынтысы исәпкә алынды. Озак сроклы чорда бюджет керемнәрен формалаштыру икътисадый үсешнең уртачарак темплары шартларында гамәлгә ашырылачак. Гомумән алганда, бюджет керемнәрен формалаштыру сәясәте салым һәм салым булмаган керемнәр буенча законнарны камилләштерү механизмнарын кулланып, ташламаларның нәтиҗәлелеген бәяләүгә, дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне файдалану нәтиҗәлелеген арттыруга системалы якын килүгә нигезләнә.

2034 елга кадәр Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының төп керем чыганаклары саклана. Бу – табышка салым, физик затлар керемнәренә салым,

акцизлар, мөлкәткә салым.

Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты баланслы булуын тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджетына керемнәрне мобилизацияләү буенча киңәйтелгән чаралар комплексын алга таба гамәлгә ашыру күздә тотыла.

Керемнәр үсеше эшлекле климатны яхшырту, сәнәгать җитештерүен үстерү, республика икътисадына инвестицияләр күләме арту, керемнәр белән идарә итү нәтиҗәлелеген арттыру исәбенә тәэмин ителәчәк.

Татарстан Республикасының озак сроклы бюджет сәясәтен гамәлгә ашырганда төбәк һәм җирле бюджетларның тотрыклылыгын тәэмин итү, бюджет законнары таләпләрен һәм чикләүләрен катгый үтәү, кабул ителгән чыгым йөкләмәләрен максатчан һәм нәтиҗәле үтәү, эчке чыганакларны мобилизацияләү, нәтиҗәсез чыгымнарны киметү, бюджет чыгымнарының үзара бәйләнешен билгеләү һәм аларның дәүләт сәясәтенең билгеләнгән максатларына йогынтысын арттыру бурычы саклана.

Озак сроклы чорга бюджет сәясәтен формалаштыру һәм гамәлгә ашыру түбәндәге төп бурычларны хәл итүдән гыйбарәт:

Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлекләрен һәм структураларын алга таба камилләштерү;

илкүләм проектларын берсүзсез үтәү һәм аларда каралган индикаторларга ирешү;

республиканың дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләре челтәрен оптимальләштерүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру;

дәүләт мөлкәтеннән һәм муниципаль мөлкәттән файдалану нәтиҗәлелеген арттыру;

республиканың дәүләт һәм муниципаль учреждениеләре эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүне инвентаризацияләү, аларның эшләвен тәэмин итүнең табигый һәм финанс нормаларын (нормативларын) куллану өлкәсен киңәйтү;

икътисадның реаль секторына дәүләт ярдәме күрсәтү өлкәсендә бюджет сәясәтен камилләштерү, юридик затларга субсидияләр бирү нәтиҗәлелеген бәяләү;

дәүләткә карамаган (муниципаль булмаган) оешмаларны социаль-мәдәни өлкәгә, шул исәптән дәүләт-хосусый партнерлыгы, муниципаль-хосусый партнерлык кысаларында җәлеп итү темпларын арттыру;

халыкка социаль ярдәм күрсәтү чаралары нәтиҗәлелеген арттыру;

бюджетара трансфертлар бирүнең һәм алардан файдалануның нәтиҗәлелеген һәм эффективлыгын арттыру;

сатып алулар өлкәсендә алдан һәм аннан соңгы контроль процедураларын камилләштерү;

дәүләт секторларында һәм муниципаль секторларда финанс менеджментының сыйфатын яхшырту;

иҗтимагый финансларның ачык һәм үтә күренмәле булуын, ихтыяри салым даирәләрен киңәйтүне, гражданнарны бюджет мәсьәләләрен хәл итү буенча фикер алышу һәм алар буенча карар кабул итү, аларның эффективлыгын һәм нәтиҗәлелеген җәмәгатьчелек контролендә тоту процедураларына киң җәлеп итүне тәэмин итү.

Фаразлана торган чорга Татарстан Республикасы бурыч сәясәтенең төп

максатлары һәм бурычлары:

Татарстан Республикасының финанс тотрыклылыгы һәм түләү сәләте сакланышын икътисадый яктан имин дәрәҗәдә тәэмин итә торган бурыч йөкләнеше дәрәҗәсендә тәэмин итү;

еллар буенча бурыч йөкләнешен тигез итеп бүлү;

хезмәт күрсәтү кыйммәтен минимальләштерү максатларында дәүләт бурычы структурасын оптимальләштерү;

бюджет кредитлары буенча бурычны реструктуризацияләү шартларын катгый үтәү;

федераль бюджеттан алынган бюджет кредитлары буенча килешүләрдә билгеләнгән чикләүләрне үтәү.

Татарстан Республикасының
икътисадый үсеше сценарийлары тасвирламасы

2034 елга кадәр Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең озак сроклы фаразы, республиканың 2026 – 2028 елларга үсеш фаразы параметрларын исәпкә алып, ике (база һәм консерватив) вариант составында формалаштырылды, ул 2025 елның 12 сентябрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышында хупланды (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2026 – 2028 елларга Татарстан Республикасын социаль-икътисадый үстерү фаразының төп параметрлары турында, 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасының бер-ләштерелгән бюджеты фаразы, 2026 елга, 2027 һәм 2028 еллар план чорына Татарстан Республикасының Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты проекты хакында» 2025 ел, 16 сентябрь, 699 нчы карары).

Демография күрсәткечләре

Фаразның база варианты буенча 2034 елга Татарстан Республикасының даими халкы саны (уртача еллык) фаразлана торган уңай миграция үсеше һәм туучылар исәбенә 4 035,6 мең кеше тәшкил итәчәк.

Халык сакланышын тәэмин итү бурычын хәл итү кысаларында төп игътибар туучылар санын стимуллаштыру буенча системалы чараларны гамәлгә ашыруга, беренчел медицина-санитария ярдәменнән һәркем файдалану мөмкинлеген арттыруга һәм аның сыйфатын яхшыртуга, медицина ярдәменең сыйфатын яхшырту буенча гомумсистемалы чаралар исәбенә үлүчеләр санын киметүгә бирелә.

Миграция сәясәте кысаларында басым хезмәт базары ихтыяҗларына да, халык санын саклап калу максатларында да сыйфатлы миграция артуын тәэмин итүгә юнәлтелә: хезмәт мигрантларын исәпкә алуның «реестрлы» моделен кертү, Россия белеме булган белгечләр өчен даими яшәү статусын модернизацияләү һәм чит ил студентларына ярдәм итү, репатриация өчен мөмкинлекләрне киңәйтү, миграциягә кадәр әзерлек үзәкләрен актив файдалану, чит ил гражданнарын адаптацияләүнең төбәк программаларын эшләү.

Фаразның консерватив варианты буенча 2034 елга Татарстан Республикасының даими халык саны (уртача еллык) 4 034,0 мең кеше тәшкил итәчәк.

Икътисадый күрсәткечләр

Озак сроклы перспективада Татарстан Республикасының тулаем төбәк продукты динамикасы билгеләнә торган икътисадның төп секторларын үстерү фаразлары түбәндәге характеристикалардан гыйбарәт.

Эшчәнлекнең җитештерү төрләрен үстерүнең фараз параметрларын исәпләгәндә, бер яктан, товарларның һәм хезмәт күрсәтүләрнең глобаль базарларында конкуренция артуы, сату һәм продукция китерү базарларында киеренкелек, икенче яктан – төп фондларны техник модернизацияләү һәм яңарту хисабына производстволарның конкурентлык сәләтен арттыруга, яңа югары нәтиҗәле производстволар булдыруга һәм югары технологияле продукция чыгаруны үзләштерүгә, шулай ук импортны алыштыру процессларын киңәйтүгә юнәлтелгәнлек исәпкә алынды.

Фаразның база варианты икътисадый сәясәт чараларын нәтиҗәле гамәлгә ашыруны, дустанә дәүләтләрдән перспективалы партнерлар белән тышкы икътисадый хезмәттәшлекне киңәйтүне, фәнни-технологик үсешне, җитештерү-логистика чылбырларын структур үзгәртеп коруны, тотрыклы озак вакытлы үсеш өчен шартлар тудыруны күздә тота.

2026 – 2028 елларда фаразның база варианты буенча тулаем төбәк продуктының уртача еллык үсеш темплары чагыштырма бәяләрдә 102,3 процент, 2029 – 2034 елларда 103,0 процент булыр дип фаразлана.

2026 – 2028 елларда сәнәгать җитештерүе уртача чагыштырма бәяләрдә 102,0 процент дәрәҗәсендә, 2029 – 2034 елларда – 102,8 процент дәрәҗәсендә үсәчәк.

Фаразга караганда, сәнәгать җитештерүе үсешенә нефть-газ химиясе һәм машина төзелеше комплекслары, башка тармаклар үсешендә энергетика төп өлеш кертәчәк. Фаразланган чорда кайбер эре инвестиция проектларын планлаштырылган куәткә чыгару көтелә. Республикада алгарышлы үсеш территорияләре, махсус икътисадый зоналар, сәнәгать парклары оештырылды һәм уңышлы үсеш алды.

2026 – 2028 елларда авыл хуҗалыгы продукциясе күләмнәре үсешенең уртача еллык темплары 2029 – 2034 елларда Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 8 апрель, 235 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгын үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын җайга салу» Татарстан Республикасы дәүләт программасы нигезендә чагыштырма бәяләрдә 101,6 процент дәрәҗәсендә фаразлана, чагыштырма бәяләрдә 100,8 процент дәрәҗәсендә карала.

«Төзелеш» эшчәнлек төре буенча башкарылган эшләр күләме үсешенең уртача еллык темплары 2026 – 2028 елларда фараз буенча чагыштырма бәяләрдә 101,1 процент, 2029 – 2034 елларда – 101,5 процент тәшкил итәчәк.

2026 – 2028 елларда ваклап сату әйләнеше уртача алганда чагыштырма бәяләрдә – 103,0 процент, 2029 – 2034 елларда 103,6 процент дәрәҗәсендә үсәчәк.

2026 – 2028 елларда төп капиталга инвестицияләр үсешенең уртача еллык темплары чагыштырма бәяләрдә 101,7 процент, 2029 – 2034 елларда 103,0 процент дәрәҗәсендә булыр дип фаразлана.

Фаразның консервив вариантында икътисад үсеше уртача дәрәҗәдә озак

сроклы темпларда булуы белән характерлана.

2026 – 2028 елларда тулаем төбәк продуктының уртача еллык үсеш темплары чагыштырма бәяләрдә – 101,7 процент, 2029 – 2034 елларда 102,1 процент дәрәҗәсендә фаразлана.

2026 – 2028 елларда фараз нигезендә сәнәгать җитештерүе уртача алганда чагыштырма бәяләрдә – 100,6 процент, 2029 – 2034 елларда 101,8 процент дәрәҗәсендә артачак.

2026 – 2028 елларда авыл хуҗалыгы продукциясенең уртача еллык үсеш темплары чагыштырма бәяләрдә – 101,6 процент, 2029 – 2034 елларда 100,8 процент дәрәҗәсендә фаразлана.

«Төзелеш» эшчәнлек төре буенча башкарылган эшләр күләме үсешенең уртача еллык темплары 2026 – 2028 елларда фараз буенча чагыштырма бәяләрдә 98,6 процент, 2029 – 2034 елларда – 99,0 процент тәшкил итәчәк.

2026 – 2028 елларда ваклап сату әйләнеше уртача чагыштырма бәяләрдә 102,5 процент, 2029 – 2034 елларда 102,9 процент дәрәҗәсендә артачак.

2026 – 2028 елларда төп капиталга инвестицияләр үсеше темпы уртача алганда чагыштырма бәяләрдә 101,3 процент, 2029 – 2034 елларда 102,6 процент дәрәҗәсендә фаразлана.

## Хезмәт һәм халыкның эш белән тәэмин ителеше күрсәткечләре

Татарстан Республикасында озак сроклы перспективада социаль күрсәткечләрне яхшырту – икътисадта эш белән тәэмин ителүчеләр санын арттыру һәм эшсезлек дәрәҗәсен киметү фаразлана.

Республикага югары квалификацияле белгечләр җәлеп итү буенча актив дәүләт сәясәтен һәм хәзерге вакытта хезмәт базарында тәкъдим ителмәгән халык катламнарын хезмәт эшчәнлегенә җәлеп итүне стимуллаштыруны күздә тоткан база варианты буенча яңа производстволарны гамәлгә кертүне, кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүне исәпкә алып, 2034 елда икътисадта эшләүчеләр санын 2 061,1 мең кешегә кадәр арттыру фаразлана.

База варианты буенча 2034 елда эшсезлек дәрәҗәсе (Халыкара хезмәт оешмасы методологиясе буенча) 1,6 процент дәрәҗәсендә фаразлана.

Консерватив вариант буенча 2034 елда республикада икътисадта эшләүчеләр саны 2 051,1 мең кеше тәшкил итәчәк.

Консерватив вариант буенча 2034 елда эшсезлек дәрәҗәсе (Халыкара хезмәт оешмасы методологиясе буенча) 1,7 процент дәрәҗәсендә фаразлана.

## Агымдагы чорда бюджет фаразын формалаштыру шартлары, озак сроклы чорга Татарстан Республикасы бюджетының төп характеристикалары фаразы

2023 – 2034 елларга керемнәр һәм чыгымнар буенча Татарстан Республикасының бюджет фаразы 2034 елга кадәрге Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең озак сроклы фаразы нигезендә ике – база һәм консерватив вариантларда эшләнде.

## Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре

Татарстан Республикасы бюджеты керемнәрен фаразлаганда Россия Федерациясе законнарына кертелгән үзгәрешләр исәпкә алынды.

Татарстан Республикасы бюджетының төп салым керемнәре буенча керемнәр фаразы 2034 елга кадәр Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсеше фаразына салынган икътисадый күрсәткечләр динамикасыннан чыгып төзелде.

Татарстан Республикасы бюджетының кайбер керемнәре өчен инфляция күләменә ясалган индексация яки тулаем эчке продуктның күтәлә торган үсеше исәпкә алынды.

## Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары

Бюджет фаразын эшләү кысаларында Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнарының исәп-хисабы, инфляция күләменә, шул исәптән Татарстан Республикасы дәүләт программалары буенча ясалган индексацияне исәпкә алып, Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары һәм Татарстан Республикасы законнары шартларында гамәлгә ашырылды.

Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт программалары исемлеген раслау турында» 2023 ел, 22 декабрь, 1667 нче карары белән расланды.

## Бюджет фаразын гамәлгә ашыру барышында барлыкка килә торган төп рисклар, һәм аларны профилактикалау механизмнары

Республиканың бюджет параметрларын бәяләү һәм аларның балансссыз булу рискларын минимальләштерү өчен шартлар тудыру мөмкинлеге стабильле озак сроклы бюджет тотрыклылыгын тәэмин итүнең мөһим факторлары булып тора.

Бюджетка яный торган куркынычларны минимальләштерүнең гомуми алымнары, кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру чыгымнарын киметмичә, Татарстан Республикасының гамәлдәге чыгым йөкләмәләрен тәэмин итү мөмкинлегеннән гыйбарәт.

Бюджет фаразын гамәлгә ашыру рисклары халыкара финанс һәм икътисадый тотрыксызлык шартларында Татарстан Республикасының бюджет системасы үсешенә йогынты ясый торган кайбер тышкы һәм эчке факторлар барлыкка килүгә бәйле.

Бюджет рискларын профилактикалау тиешле рискларны тормышка ашыруның тискәре нәтиҗәләрен минимальләштерү буенча алдан ук ачыклау һәм чаралар күрү белән тәэмин ителә.

Икътисадый тотрыксызлык шартларында Татарстан Республикасы бюджет системасы өчен аеруча иң тискәре нәтиҗәләргә һәм рискларга түбәндәгеләр керә:

республика социаль-икътисадый үсешенең тулаем төбәк продукты, табышлы оешмалар табышы, хезмәт хакы фонды, шулай ук төп капиталга инвестицияләр кебек фаразлана торган параметрларына (динамикасына һәм күләмнәренә) ирешмәү;

эшсезлек арту;

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр һәм бюджеттан тыш эшчәнлектән керемнәр кимү;

федераль бюджеттан бирелә торган бюджетара трансфертларны киметү;

өстәмә чыгым йөкләмәләрен тапшыру;

Россия Федерациясе субъектлары бюджетларын «авырайта торган» Россия Федерациясе салым һәм бюджет законнарына үзгәреш кертү.

Бюджет рискларын минимальләштерү чаралары:

Татарстан Республикасының керем потенциалын арттыру;

Республика Татарстан һәм җирле бюджетларның керем өлешен социаль әһәмиятле чыгымнарны башкару өчен максималь тулыландыру;

Татарстан Республикасы дәүләт бурычын икътисадый яктан имин булган дәрәҗәдә тәэмин итү;

Татарстан Республикасы бюджеты һәм җирле бюджетлар үтәлешенә җентекле анализ ясау;

халыкның эш белән тәэмин ителешенә булышлык күрсәтү өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыру.

Озак сроклы чорда Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль финанслары белән идарә итү сыйфатын яхшырту һәм бюджет акчасын файдалану нәтиҗәлелеген арттыру эшен дәвам итәргә кирәк.

# 2034 елга кадәр Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең озак сроклы фаразы буенча төп күрсәткечләр

(база варианты)

| Күрсәткечләр | Үлчәү берәмлеге | Фараз | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел | 2031 ел | 2032 ел | 2033 ел | 2034 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| Демография күрсәткечләре | | | | | | | | | | |
| Даими халык саны (уртача еллык) | мең кеше | 4 020,5 | 4 022,2 | 4 024,1 | 4 026,0 | 4 027,9 | 4 029,8 | 4 031,7 | 4 033,6 | 4 035,6 |
| Үсеш темплары | үткән елга карата процент | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 |
| Тулаем төбәк продукты | | | | | | | | | | |
| Тулаем төбәк продукты | млн.сум | 5 783 844,2 | 6 126 676,9 | 6 503 324,7 | 6 949 400,9 | 7 431 056,6 | 7 944 492,5 | 8 475 244,5 | 9 033 391,7 | 9 630 708,6 |
| Тулаем төбәк продуктының физик күләме индексы | үткән елга карата процент | 102,1 | 102,3 | 102,4 | 102,8 | 103,0 | 103,0 | 103,1 | 103,1 | 103,1 |
| Сәнәгать җитештерүе | | | | | | | | | | |
| Үз җитештерүендәге төяп җибәрелгән товарлар, үз көчләре белән башкарылган эшләр һәм күрсәтелгән хезмәтләр | млн.сум | 5 929 508,2 | 6 254 223,4 | 6 621 961,6 | 7 058 530,1 | 7 540 680,3 | 8 061 450,8 | 8 615 604,1 | 9 214 638,6 | 9 857 772,1 |
| Сәнәгать җитештерүе индексы | үткән елга карата процент | 101,7 | 102,0 | 102,2 | 102,6 | 102,7 | 102,8 | 102,8 | 102,9 | 102,9 |
| Авыл хуҗалыгы | | | | | | | | | | |
| Авыл хуҗалыгы продукциясе | млн.сум | 373 713,2 | 379 397,8 | 385 936,9 | 391 707,6 | 397 571,6 | 399 559,5 | 401 557,2 | 403 565,0 | 405 582,9 |
| Авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү индексы | үткән елга карата процент | 101,5 | 101,5 | 101,7 | 101,5 | 101,5 | 100,5 | 100,5 | 100,5 | 100,5 |
| Төзелеш | | | | | | | | | | |
| «Төзелеш» икътисадый эшчәнлек төре буенча башкарылган эшләр күләме | млн.сум | 1 011 093,7 | 1 067 158,9 | 1 129 742,4 | 1 195 996,1 | 1 266 135,3 | 1 340 387,9 | 1 418 994,9 | 1 502 211,9 | 1 590 309,1 |
| «Төзелеш» эшчәнлеге төре буенча башкарылган эшләрнең физик күләме индексы | үткән елга карата процент | 100,8 | 101,0 | 101,5 | 101,5 | 101,5 | 101,5 | 101,5 | 101,5 | 101,5 |
| Товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр базары | | | | | | | | | | |
| Ваклап сату әйләнеше | млн.сум | 1 949 909,3 | 2 088 742,9 | 2 239 633,7 | 2 415 400,2 | 2 604 960,8 | 2 806 688,9 | 3 024 038,9 | 3 258 220,5 | 3 510 537,1 |
| Ваклап сату әйләнешенең физик күләме индексы | үткән елга карата процент | 102,8 | 103,0 | 103,1 | 103,7 | 103,7 | 103,6 | 103,6 | 103,6 | 103,6 |
| Инвестицияләр | | | | | | | | | | |
| Төп капиталга инвестицияләр | млн.сум | 1 704 435,0 | 1 809 680,4 | 1 936 571,6 | 2 108 608,9 | 2 289 280,8 | 2 478 215,1 | 2 677 533,0 | 2 887 253,5 | 3 110 366,0 |
| Төп капиталга инвестиция-ләрнең физик күләме индексы | үткән елга карата процент | 100,8 | 101,7 | 102,6 | 103,6 | 103,3 | 103,0 | 102,8 | 102,6 | 102,5 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Хезмәт һәм халыкның эш белән тәэмин ителеше | | | | | | | | | | |
| Икътисадта эш белән тәэмин ителүчеләр саны (уртача еллык) (хезмәт ресурслары балансы методологиясендә) | мең кеше | 2 052,8 | 2 065,0 | 2 062,3 | 2 059,1 | 2 061,1 | 2 061,5 | 2 060,7 | 2 060,8 | 2 061,1 |
| Эшсезлек дәрәҗәсе (Халыкара хезмәт оешмасы методологиясе буенча) | эш белән тәэмин ителүчеләргә карата процентта | 2,0 | 1,9 | 1,9 | 1,7 | 1,7 | 1,6 | 1,6 | 1,6 | 1,6 |

# 2034 елга кадәр Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенең озак сроклы фаразы буенча төп күрсәткечләр

(консерватив вариант)

| Күрсәткечләр | Үлчәү берәмлеге | Фараз | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2026 ел | 2027 ел | 2028 ел | 2029 ел | 2030 ел | 2031 ел | 2032 ел | 2033 ел | 2034 ел |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
| Демография күрсәткечләре | | | | | | | | | | |
| Даими халык саны (уртача еллык) | мең кеше | 4 019,6 | 4 020,9 | 4 022,8 | 4 024,6 | 4 026,4 | 4 028,3 | 4 030,2 | 4 032,1 | 4 034,0 |
| Үсеш темплары | узган елга карата процент | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 | 100,0 |
| Тулаем төбәк продукты | | | | | | | | | | |
| Тулаем төбәк продукты | млн.сум | 5 739 732,3 | 6 054 909,5 | 6 403 559,1 | 6 771 711,8 | 7 166 189,5 | 7 576 326,3 | 8 015 929,2 | 8 482 203,3 | 8 972 787,4 |
| Тулаем төбәк продуктының физик күләме индексы | узган елга карата процент | 101,0 | 102,0 | 102,1 | 102,0 | 102,1 | 102,1 | 102,1 | 102,1 | 102,1 |
| Сәнәгать җитештерүе | | | | | | | | | | |
| Үз җитештерүеңдәге төяп җибәрелгән товарлар, үз көчләре белән башкарылган эшләр һәм күрсәтелгән хезмәтләр | млн.сум | 5 908 645,1 | 6 203 818,2 | 6 537 909,7 | 6 889 068,9 | 7 264 087,5 | 7 665 681,1 | 8 093 690,2 | 8 546 752,4 | 9 015 658,1 |
| Сәнәгать җитештерүе индексы | узган елга карата процент | 98,6 | 101,6 | 101,7 | 101,7 | 101,8 | 101,8 | 101,8 | 101,9 | 101,9 |
| Авыл хуҗалыгы | | | | | | | | | | |
| Авыл хуҗалыгы продукциясе | млн.сум | 373 713,2 | 379 397,8 | 385 936,9 | 391 707,6 | 397 571,6 | 399 559,5 | 401 557,2 | 403 565,0 | 405 582,9 |
| Авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү индексы | узган елга карата процент | 101,5 | 101,5 | 101,7 | 101,5 | 101,5 | 100,5 | 100,5 | 100,5 | 100,5 |
| Төзелеш | | | | | | | | | | |
| «Төзелеш» икътисадый эшчәнлек төре буенча башкарылган эшләр күләме | млн.сум | 985 013,9 | 1 013 899,5 | 1 046 922,2 | 1 081 020,4 | 1 116 229,3 | 1 152 584,8 | 1 190 124,5 | 1 228 886,9 | 1 268 911,7 |
| «Төзелеш» эшчәнлеге төре буенча башкарылган эшләрнең физик күләме индексы | узган елга карата процент | 98,2 | 98,5 | 99,0 | 99,0 | 99,0 | 99,0 | 99,0 | 99,0 | 99,0 |
| Товарлар һәм хезмәт күрсәтүләр базары | | | | | | | | | | |
| Ваклап сату әйләнеше | млн.сум | 1 936 575,8 | 2 064 389,8 | 2 209 227,4 | 2 364 226,8 | 2 530 100,9 | 2 707 612,8 | 2 897 578,9 | 3 100 873,1 | 3 318 430,3 |
| Ваклап сату әйләнешенең физик күләме индексы | узган елга карата процент | 102,0 | 102,5 | 102,9 | 102,9 | 102,9 | 102,9 | 102,9 | 102,9 | 102,9 |
| Инвестицияләр | | | | | | | | | | |
| Төп капиталга инвестицияләр | млн.сум | 1 664 522,5 | 1 761 978,7 | 1 882 646,4 | 2 043 957,2 | 2 212 645,0 | 2 388 278,1 | 2 570 322,2 | 2 758 138,2 | 2 950 981,7 |
| Төп капиталга инвестицияләрнең физик күләме индексы | узган елга карата процент | 100,2 | 101,4 | 102,4 | 103,3 | 103,0 | 102,7 | 102,4 | 102,1 | 101,8 |

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Хезмәт һәм халыкның эш белән тәэмин ителеше | | | | | | | | | | |
| Икътисадта эш белән тәэмин ителүчеләр саны (уртача еллык) (хезмәт ресурслары балансы методологиясендә) | мең кеше | 2 046,7 | 2 052,8 | 2 051,9 | 2 050,2 | 2 051,0 | 2 051,3 | 2 050,9 | 2 051,0 | 2 051,1 |
| Эшсезлек дәрәҗәсе (Халыкара хезмәт оешмасы методологиясе буенча) | эш белән тәэмин ителүчеләргә карата процентта | 2,0 | 2,1 | 1,9 | 1,8 | 1,8 | 1,7 | 1,7 | 1,7 | 1,7 |

# Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының һәм Татарстан Республикасы бюджетының төп характеристикалары фаразы

(база варианты, млрд.сум)

| Төп характеристикаларның исеме | 2023 ел | | 2024 ел | | 2025 ел | | 2026 ел | | 2027 ел | | 2028 ел | | 2029 ел | | 2030 ел | | 2031 ел | | 2032 ел | | 2033 ел | | 2034 ел | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты |
| Керемнәр – барлыгы, шул исәптән: | 565,7 | 486,8 | 697,1 | 594,3 | 714,2 | 597,8 | 659,0 | 552,2 | 691,4 | 578,9 | 739,6 | 620,9 | 757,9 | 635,9 | 778,0 | 652,4 | 798,7 | 669,3 | 820,7 | 687,3 | 843,4 | 705,8 | 866,8 | 724,9 |
| салым һәм салым булмаган | 481,1 | 407,2 | 593,4 | 499,1 | 586,7 | 480,9 | 566,1 | 459,1 | 596,4 | 483,7 | 636,1 | 517,2 | 653,9 | 531,7 | 673,5 | 547,7 | 693,7 | 564,1 | 715,2 | 581,6 | 737,4 | 599,6 | 760,3 | 618,2 |
| кире кайтарылмый торган түләүләр | 84,6 | 79,6 | 103,7 | 95,2 | 127,5 | 116,9 | 92,9 | 93,1 | 95,0 | 95,2 | 103,5 | 103,7 | 104,0 | 104,2 | 104,5 | 104,7 | 105,0 | 105,2 | 105,5 | 105,7 | 106,0 | 106,2 | 106,5 | 106,7 |
| Чыгымнар – барлыгы, шул исәптән: | 589,4 | 510,2 | 675,3 | 578,3 | 731,7 | 615,1 | 672,8 | 566,0 | 708,4 | 595,9 | 758,3 | 639,6 | 776,5 | 654,5 | 796,5 | 670,9 | 817,1 | 687,7 | 839,0 | 705,6 | 861,6 | 724,0 | 884,9 | 743,0 |
| Татарстан Республикасы дәүләт программаларын финанс белән тәэмин итү, | | 472,9 | | 560,2 | | 592,3 | | 512,5 | | 525,1 | | 549,4 | | 562,2 | | 576,3 | | 590,7 | | 606,1 | | 621,9 | | 638,2 |
| илкүләм проектларны финанс белән тәэмин итүне дә кертеп | | 46,0 | | 47,0 | | 46,5 | | 53,0 | | 53,4 | | 57,8 | | 59,1 | | 60,6 | | 62,1 | | 63,8 | | 65,4 | | 67,1 |
| Дефицит (профицит) | -23,7 | -23,4 | 21,8 | 16,0 | -17,5 | -17,3 | -13,8 | -13,8 | -17,0 | -17,0 | -18,7 | -18,7 | -18,6 | -18,6 | -18,5 | -18,5 | -18,4 | -18,4 | -18,3 | -18,3 | -18,2 | -18,2 | -18,1 | -18,1 |

# Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетының һәм Татарстан Республикасы бюджетының төп характеристикалары фаразы

(консерватив вариант, млрд.сум)

| Төп характеристикаларның исеме | 2023 ел | | 2024 ел | | 2025 ел | | 2026 ел | | 2027 ел | | 2028 ел | | 2029 ел | | 2030 ел | | 2031 ел | | 2032 ел | | 2033 ел | | 2034 ел | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты | Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты | Татарстан Республикасы бюджеты |
| Керемнәр – барлыгы, шул исәптән: | 565,7 | 486,8 | 697,1 | 594,3 | 714,2 | 597,8 | 648,9 | 544,1 | 677,7 | 567,8 | 731,0 | 613,9 | 744,0 | 624,6 | 758,0 | 636,0 | 772,2 | 647,7 | 786,7 | 659,6 | 801,5 | 671,7 | 816,6 | 684,1 |
| салым һәм салым булмаган | 481,1 | 407,2 | 593,4 | 499,1 | 586,7 | 480,9 | 556,0 | 451,0 | 582,7 | 472,6 | 627,5 | 510,2 | 640,0 | 520,4 | 653,5 | 531,3 | 667,2 | 542,5 | 681,2 | 553,9 | 695,5 | 565,5 | 710,1 | 577,4 |
| кире кайтарылмый торган түләүләр | 84,6 | 79,6 | 103,7 | 95,2 | 127,5 | 116,9 | 92,9 | 93,1 | 95,0 | 95,2 | 103,5 | 103,7 | 104,0 | 104,2 | 104,5 | 104,7 | 105,0 | 105,2 | 105,5 | 105,7 | 106,0 | 106,2 | 106,5 | 106,7 |
| Чыгымнар – барлыгы, шул исәптән: | 589,4 | 510,2 | 675,3 | 578,3 | 731,7 | 615,1 | 672,8 | 568,0 | 708,4 | 598,5 | 758,3 | 641,2 | 771,2 | 651,8 | 785,1 | 663,1 | 799,2 | 674,7 | 813,6 | 686,5 | 828,3 | 698,5 | 843,3 | 710,8 |
| Татарстан Республикасы дәүләт программаларын финанс белән тәэмин итү, | | 472,9 | | 560,2 | | 592,3 | | 514,3 | | 527,4 | | 550,8 | | 559,9 | | 569,6 | | 579,6 | | 589,7 | | 600,0 | | 610,6 |
| илкүләм проектларны финанс белән тәэмин итүне дә кертеп | | 46,0 | | 47,0 | | 46,5 | | 53,2 | | 53,6 | | 57,9 | | 58,9 | | 59,9 | | 61,0 | | 62,0 | | 63,1 | | 64,2 |
| Дефицит (профицит) | -23,7 | -23,4 | 21,8 | 16,0 | -17,5 | -17,3 | -23,9 | -23,9 | -30,7 | -30,7 | -27,3 | -27,3 | -27,2 | -27,2 | -27,1 | -27,1 | -27,0 | -27,0 | -26,9 | -26,9 | -26,8 | -26,8 | -26,7 | -26,7 |

_______________